**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.12.2020 г. Казань № 146од

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының аларны биләү коррупция куркынычы белән бәйле булган, дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2015 елның 11 мартындагы 01-02/170 номерлы боерыгы белән расланган исемлегенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының аларны биләү коррупция куркынычы белән бәйле булган, дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2015 елның 11 мартындагы 01-02/170 номерлы боерыгы белән расланган (2015 елның 22 декабрендәге 01-02/821 номерлы, 2016 елның 5 октябрендәге 01-02/265 номерлы, 2018 елның 9 гыйнварындагы 1 од номерлы, 2018 елның 23 августындагы 91 од номерлы боерыклар белән кертелгән үзгәрешләр белән) исемлегенә, 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«5. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә вазыйфаларның әйдәп баручы төркемендә «белгечләр» категориясе вазыйфалары:

түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне оештыру һәм планлаштыру бүлегенең әйдәп баручы советнигы;

җирле үзидарә һәм муниципаль регистр алып бару өлкәсендә норматив хокукый эш бүлегенең әйдәп баручы советнигы;

җирле үзидарә өлкәсендә территориаль оештыру һәм тикшереп тору мәсьәләләре бүлегенең әйдәп баручы советнигы;

җирле үзидарә органнарына хокукый консультацион-методик ярдәм күрсәтү бүлегенең әйдәп баручы советнигы;

кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне оештыру һәм планлаштыру бүлегенең аның вазыйфасына түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын каплау турында адвокатлар тәкъдим иткән реестрларның тулылыгын һәм нигезлелеген тикшерүне гамәлгә ашыру керә торган әйдәп баручы консультанты;

җирле үзидарә һәм муниципаль регистр алып бару өлкәсендә норматив хокукый эш бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне оештыру һәм планлаштыру бүлегенең әйдәп баручы белгеч-эксперты.».

Министр Р.И. Заһидуллин